# КЕРЕШ СҮЗ,
# АНЫ УКЫМАСАҢ ДА БУЛА

Балалар, мөгаен, сезнең һәркайсыгызның да яраткан уенчыгы бардыр. Бәлки әле, икәү, хәтта бишәүдер. Минем, мәсәлән, бәләкәй чакта яраткан уенчыгым өчәү иде: Гена исемле бик зур резин крокодилым, Галя исемле кечкенә пластмасс курчагым, аннары — Чебурашка дигән мәзәгрәк исемле килбәтсез бер плюш җәнлегем. Чебурашканы уенчыклар фабрикасында ясаган булсалар да, аны шулкадәр начар итеп ясаганнар, хәтта аның кем икәнлеген дә аерып булмаслык иде. Кем иде соң ул: куянмы, этме, песиме, әллә инде Австралия көнгерәсеме? Күзләре ябалакныкы кебек зур, сары, башы куяннныкыдай йомры, койрыгы исә нәни аю балаларыныкы кебек кечкенә генә, йомшак. Әти-әнием Чебурашканы әлегәчә фәнгә билгеле булмаган, эссе тропик  урманнарда гына очрый торган җәнлек дип аңлаталар. Мин баштарак фәнгә билгеле булмаган бу Чебурашкадан бик курка, шуңа күрә аның белән бер бүлмәдә калырга да теләми идем. Торабара гына аның бу шикле кыяфәтенә ияләштем, крокодил Гена белән пластмасс курчак Галяны яраткан кебек үк ярата да башладым. Ул вакыттан соң күп гомерләр үтте, ләкин мин үземнең кечкенә дусларымны барыбер хәтерлим, шуңа күрә алар турында тулы бер китап та язып чыктым. Әлбәттә инде, китапта алар уенчык түгел, тере җан ияләре булачак.

# БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

Бер куе тропик урманда яшәгән, ди, булган, ди, мәзәк кыяфәтле бер нәни җәнлек. Аның исеме Чебурашка икән. Дөресрәге, тропик урманда яшәгән чакта, аның бернинди исеме дә булмаган. Ә «Чебурашка» дигән исемне аңа соңрак, урманнан китеп, кешеләр белән очрашкач биргәннәр. Чөнки җәнлекләргә исемне кешеләр бирәләр бит. Филгә — фил икәнлеген, жирафка — жираф икәнлеген, куянга куян икәнлеген дә кешеләр әйткән. Әмма фил, әгәр дә уйлап караган булса, үзенең фил икәнлеген чамалаган булыр иде. Чөнки аның исеме шундый гади бит! Ә менә гиппопотам дигән катлаулы исемле җан иясенең хәле ничегрәк? Менә син үзеңнең ги-потам яисә по-потам да түгел, ә нәкъ менә гип-по-по-там икәнлегеңне чамалап кара! Менә минем җәнлегем дә шулай инде, ул беркайчан да үзенең исеме турында уйланып баш ватмаган, ә бары тик үзенең ерак тропик урманында яшәвен генә белгән. Бервакыт ул иртән иртүк уянган да, тәпиләрен аркасына куеп, бераз йөреп керергә, саф һава суларга чыгып киткән. Йөргән-йөргән дә бер зур җимеш бакчасы янында әфлисуннар тутырылган берничә әрҗә күреп алган. Күп уйлап тормыйча, шуларның берсенә кереп утырган да сыйланырга керешкән бу. Ике зур әфлисунны ашап бетергәч, тамагы туеп, кыймылдыйсы да килми башлаган. Шуңа күрә әфлисуннар өстендә үк йоклап киткән. Чебурашка шундый каты йоклаган, ди, хәтта эшчеләр килеп, әрҗәләрне кадаклап чыкканнарын да сизми калган. Аннан соң бу әфлисуннарны, Чебурашка белән бергә корабльгә төяп, ерак сәфәргә озатканнар. Әрҗәләр океан-диңгезләр буйлап шактый озак йөзгәннәр, ахыр чиктә бик зур шәһәрнең җиләк-


ТЕЛЕФОН

җимеш кибетенә барып эләккәннәр. Бер әрҗәне ачсалар, анда бернинди әфлисун юк, ә бәлки симез-юан Чебурашка гына тәгәрәп ята,ди. Сатучылар аны әлеге каютасыннан өстерәп чыгарып, өстәлгә утыртып куйганнар. Ләкин Чебурашка өстәлдә утыра алмаган: әрҗәдә бик озак ятканга күрә, аның тәпиләре оеган булган. Як-ягына карап утырган-утырган да урындыкка тәгәрәп төшкән. Урындыкта да озак утыра алмаган — идәнгә тәгәрәгән.

— Ай-яй, нинди Тиктормас икән син! — дигән кибетнең директоры. — Һич бер урында утырып тора алмыйсың!

Ә «Тиктормас» дигән сүз аның телендә «Чебурашка» икән. Шулай итеп, безнең җәнлек үзенең Чебурашка икәнлеген белгән.

— Нишләтергә инде сине хәзер? — дип сораган директор. — Әфлисун урынына сатып булмый бит инде!

— Белмим, — дигән Чебурашка. — Ничек телисез, шулай эшләгез.

Директорга Чебурашканы, култык астына кыстырып, шәһәр зоопаркына илтергә туры килгән. Тик Чебурашканы зоопаркка кабул итмәгәннәр. Беренчедән, зоопарк болай да туп-тулы икән. Икенчедән, Чебурашка фәнгә бөтенләй билгесез җәнлек булып чыккан. Аны кая куясын беркем дә белмәгән: куяннар янынамы, юлбарыслар читлегенәме, әллә инде диңгез ташбакалары белән бергәме? Ахыр чиктә директор Чебурашканы кабат култык астына кыстырган да шулай ук кибет директоры булып эшләгән ерак кардәше янына юл тоткан. Аның кибетендә бәясе төшерелгән товарлар сатыла икән.

— Ярар соң, — дигән икенче номерлы директор, — бу җәнлек ошый миңа. Ул ялгыш ясалган уенчыкка охшаган! Мин аны үземнең эшемә алып барырмын. Барасыңмы минем белән?

— Барам, — дигән Чебурашка. — Ә миңа нишләргә кирәк булачак соң?

— Витринада торып, үтеп баручыларның игътибарын җәлеп итәргә. Аңлашылдымы?

— Аңлашылды, — дигән җәнлек. — Ә мин кайда яшәрмен икән?

— Кайда яшәрсеңме?.. Һич югы, менә монда! — Директор Чебурашкага кибет янында торган иске телефон будкасын күрсәткән. — Ул синең өең булыр!

Шулай итеп, Чебурашка әлеге зур кибеттә эшли һәм шушы бәләкәй генә өйдә тора башлаган. Әлбәттә, бу өй шәһәрдә иң яхшылардан саналмаган. Әмма Чебурашка карамагында һәрвакыт автомат телефон булган, һәм ул, өеннән чыкмыйча гына, үзе теләгән теләсә кемгә чылтырата алган. Дөрес, аның чылтыратыр кешесе булмаган да инде, тик ул моның өчен бер дә борчылмаган.

